| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 8 июне** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1524** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 05 февралендәге 244 номерлы “Зеленодольск шәһәре, Союз урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында” карары үз көчен югалтуын тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 05 февралендәге 244 номерлы «Зеленодольск шәһәре, Союз урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында» карарының торак биналар милекчеләренә җибәрү вакытлары үзгәрүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 05 февралендәге 244 номерлы «Зеленодольск шәһәре, Союз урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:

-күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәлүен башкаручы органга;

- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУна;

- торак биналар милекчеләренә җибәрергә.

3. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н.Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Зеленодольск муниципаль районының интернет челтәре сайтында һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгаруны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин